СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищә авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

10.04.2019 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 56-248

пос. Октябрьский

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты турында

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына таянып һәм Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының 12 сентябрь 2018 ел №46-197, карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар чыгарды

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы тәкъдим иткән «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын хупларга, аны беренче укылышта кабул итәргә һәм тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, эшне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча кергән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

– эш төркеме рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы Азизов Ш.Р.;

– эш төркеме секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе Янгуразова А.Р.;

Эшче төркем әгъзалары:

- Фазлыева Фарида Вакифовна – «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ «Октябрьский авыл китапханәсе» 17 филиалы мөдире

- Мухамадеева Юлия Валерьевна – «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 2 нче филиалы мөдире
- Назаров Артур Сергеевич – «Октябрьский урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта)

4. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча фикер алышуларда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3 нче кушымта)

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча ачык тыңлауларны 2019 елның 27апрелендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Октябрьский поселогы, Центральная урамы, 7 нче йорт адресы буенча үткәрергә.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советына кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы                    Ш.Р. Азизов

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советының
10.04.2019 ел № 56-248 карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1.1. Октябрьский авыл җирлеге Уставының 6 статьясының 12 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:
"12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек алып бару ".

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы Ш.Р. Азизов

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советының
10.04.2019 ел № 56-248 карарына
2нче кушымта

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕН ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр 2019 елның 26 апреленә кадәр, Ф. И. О. һәм авторның яшәү урыны турындагы мәгълүматларны күрсәтеп, язма рәвештә кертелә.

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422580, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Октябрьский поселогы, Центральная урамы, 7 нче йорт, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советындагы эшче төркем сәркәтибе А. Р. Янгуразова авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр. Белешмәләр өчен телефон: 8(84379)31427

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы: Ш.Р. Азизов

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советының
10.04.2019 ел № 56-248 карарына
3нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕН ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАР ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

1. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422580, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Октябрьский бистәсе, Центральная урамы, 7 нче йорт, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетына Ш. Р. Азизовка шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» тамгалы).

2. Халык алдында чыгыш ясау хокукы белән Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Советына язмача гариза биргән авыл халкы чыгыш ясый ала.

3. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка барлык кызыксынучы җирлек халкы да булырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү халык тыңлаулары башланганчы 30 минут кала башлана.

5. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар гариза бирү вакытына карап чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

6. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

7. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

8. Халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлауларының барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

9. Халык тыңлауларында катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы: Ш.Р. Азизов